
Мөхәммәт МӘҺДИЕВ шәҗәрәсе



Мөхәммәт Мәһдиев.

Еракларга киткән кеше бер кайта,
Зиратларга киткәнне ил югалта.
Йолдызларга тиң кешедән аерылу
Озак еллар бөтен илне елата.

«Робагыйлар»дан.

«Безнең Гөберчәк*, безнең Сикертән» — дип сүз башлый иде Мөхәммәт ага авыллар турында сүз чыкканда. Гөберчәк — әдипнең туган авылы, аны «безнең Гөберчәк» дип әйтсен дә инде, ә менә Сикертәнне ник «безнең Сикертән» дигән ул? Моннан 5-6 ел чамасы элек шул авылга барып чыккач кына аңладым мин моны. Төп кода-кодагый буларак, хатыным Фәһимә белән Сикертәндә туй мәҗлесе түрендә утырырга насыйп булган иде.

Туйда җырланган җырлар әле дә булса колакта яңгырап тора. Кияү — Арча, кәләш Сарман ягыннан булгангамы, җырга бердә кытлык сизелмәде. Сарманлылар башлаган җырны — арчалылар, арчалылар яңгыраткан җырны сарманлылар күтәреп алды. Мөхәммәт Мәһдиев «Кеше китә — җыры кала» дип әйткән диләр дә, тагын җыр сузалар. Сагынып калырлык җырлар тынып тормады...

Сикертәннән 2,5 чакрымда гына булган Гөберчәк авылына да бардык. Бу ике авыл җирләрен урман полосасы бергә тегеп куйган сыман. Үзәннәр, калкулыклар узып, Мөхәммәт Мәһдиев тәгәрәп үскән урыннар белән хозурландык. Казансуга йөгерүче Кесмәс елгасының ике ягына да, бер урыннан икенче урынга сикерә-сикерә, Сикертән авылы урнашкан. Исеме дә әллә шуннан чыккан? Ә менә Гөберчәктәге инешнең исеме юк. Шулай да, Мөхәммәт Мәһдиевнең Равия исемле апасының кызы Җәүһәр бу инешнең исеме Сәбек булырга мөмкин, диде. Чөнки язучының бер әсәрендә Гөберчәктәге «Сәбек басмасы» искә алына икән.


Бу якларның матур табигате Мөхәммәт ага китапларында бик күп мәртәбә тасвирланган. Ул үзе исән чакта көлеп торган авыллар, урамнар, болыннар, таулар, су буйлары моңсу да, сагышлы да иде. Алар язучы бакый йортка күчкәннән соң, әйтерсең, ятим калганнар. Әнә, су буендагы таллар да уйга батып, толымнарын түбән төшергәннәр...

Мөхәммәт Мәһдиев бу авыллар өчен гади авылдаш яки якташ кына булмаган шул. Ул аларның бәгырь кисәге дә булган. Кем белән генә сөйләшмә, аны һәм әйткән сүзләрен искә төшерә. Сикер-

* Элек бу авылны Кече Муй исеме белән дә йөрткәннәр.

тәнне дә, Гөберчәкне дә Мөхәммәт ага бердәй якын күргән. Биредә аның гомер бишеге.

Әтисе Сөнгатулла Бәдретдин улы Мәһдиев 1884 елда Сикертәндә туган. Ул авылда мәктәп тәмамлап, Сатыш мәдрәсәсендә белем алган, аннан соң Арчада ике еллык урыс-татар мәктәбен-




Сикертән авылының 1884 елгы метрикә дәфтәренең "Вәҗүдкә килгәннәр" сәхифәсе. Өченче юлы Мөхәммәт Мәһдиевнең әтисе Сөнгатулланың туулы турында мәгълүмат саклый. ТМА, 4 ф., 608 еш, 10 б.

дә укыган. Хәрби хезмәтне 1907-1909 елларда Вильно шәһәрендә үткән. Аннан кайтып, үзе укыган Сатыш мәдрәсәсендә, бераздан соң Үзин өязендә мөгаллим булган. 1913-1914 елларда Сөнгатулла үзе туып-үскән Сикертән авылында мөгаллимлек кыла. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, чак кына сугышка китмичә кала. 1915 елда ул Гөберчәккә мулла булып килә, ә бу чорда Садрый Максуди тырышлыгы белән муллаларны хәрби хезмәттән азат итәләр, һәм үз гомерен шул авыл белән бәйли. 1916 елда өй җиткереп керә, гаилә кора. 1929 ел азагында ул муллалыгын ташларга мәҗбүр була, җиләк-җимеш үстерү, умарта үрчетү белән шөгыльләнә башлый. Моңа кадәр авылда туучы, үлү-1930 елның 1 декабре исәпләнә.

Сөнгатулла хәзрәт 1933 елның 30 гыйнварында кулга алына. Җинаять кодексының 58-11, 58-10 маддәләре буенча («Баш күтәрүгә юнәлтелгән оешмада булган»ы өчен) гаепләү белдерелә, беркая да китмәү турында 1933 елның 15 маенда имзасы алына, ниһаять, шул елның 13 декабрендә эше туктатыла. Әмма 1937 елның 19 декабрендә кабат кулга алына һәм 28 декабрьдә, ягъни 10 көннән соң, җинаять кодексының 58-10, 58-11 маддәләре буенча («контроешмада катнашкан» өчен) мөлкәтен конфискацияләп, үлем җәзасына хөкем ителә. 1938 елның 5 гыйнварында Казан шәһәрендә атыла.

1957 елның 14 февралендә аклана.



Мәһдиевләр шәҗәрәсе.

Инде белгәнебезчә, Гөберчәк авылын элек Кече Муй исеме белән йөрткәннәр, шуңа күрә Мөхәммәт Мәһдиевнең тууы Кече Муй авылы метрикәсендә. Ул Сөнгатуллин Мөхәммәт булып язылган. Бу вакытта әтисе — 45, әнисе 40 яшьтә диелгән.

Мөхәммәт әтисеннән 7 яшендә ятим кала. Гаиләдәге 8 баланың өчесе яшьли вафат була, берсе 1941 елның кышында Казанда хәрби ныгытмалар эшендә салкын тидереп, 5 ел үпкә чире белән җәфаланып дөнья куя. Габдерәшит, Рауза, Равия һәм төпчекләре Мөхәммәт исәнимин үсәләр. Әниләре Бибирабига апа балаларын укытуга күп көч куя. Ул үзе дә затлы нәселдән була. Аның исеме күренекле мәгърифәтче, китапчы Таип Яхин белән бер шәҗәрәдә. Бибирабига апаның бабасы (әтисе Мөхәммәтсафаның атасы) Мөхәммәтгариф белән Таип бертуганнар. Алар — Теләче ягындагы Күкчә авылы мулласы Яхъя хәзрәт балалары. Яхин фамилиясе шул заттан килә. Мөхәммәтгариф каләм иясе булган, ул шигырьләр дә язган.

Каләм иясе дигәннән, Мөхәммәт Мәһдиевнең әтисе Сөнгатулла хәзрәт өчен дә каләм хезмәте чит-ят булмаган. Аның көндәлек матбугатта мәкаләләре күренгәләп торган. Әйтик, 1911-1913 елларда Казан губернасы авылларында «кыз сату» модага кергән. Ачлык дигән булып, күп кенә чибәр кызларны Урта Азия якларына сатып, «артык тамак»тан котылалар, янәсе. Ә ул кызларны байлар өченче, дүртенче хатынлыкка алганнар. Мондый сатып алуны оештыручы маклерлар Сикертәнгә дә килеп чыгалар. Сөнгатулла Мәһдиевнең шундый гамәлләргә каршы язылган мәкаләсе 1913 елда «Йолдыз» газетасында дөнья күргән.

Хәзер Гөберчәк авылында Мөхәммәт Мәһдиев исемен мәңгеләштерү өчен күп эш эшләнгән. Аның туып-үскән йортына (бу йортны 1960 елда язучы үзе мари урманнарыннан нарат бүрәнәләр алып кайтып бик әйбәтләп сипләткән булган) истәлек тактасы куелган. Янәшәсендә Мөхәммәт Мәһдиевкә музей-йорт ачканнар. Төз нарат бүрәнәләрдән буралган бу бинаны чын балта осталары эшләгән. Музей ачылу көне бөтен тирә-як авыллар өчен олы вакыйга булган. Олысы да, кечесе дә үзләре яраткан язучыга тирән хөрмәт белән бу истәлекле тантанага җыелган. Инде шактый гына экспонатлар да тупланган. Язучының шәхси әйберләре, нәшер ителгән китаплары шушы музейда урын алган.

Юксынулы-сагышлы уйлар белән авыл зиратына юнәлдек. Капкадан кергәч үк язучының кабер ташы. Анда «Мөхәммәт Сөнгатулла улы Мәһдиев. Галим һәм язучы, 1929-1995» дип язылган. Бу кабер ташы утыртылган нигез ташына:

«Атадин бала яшь кала,

Бик күп эшләр башкара, — дигән сүзләр уелган...

Белгәнебезне укып, яраткан язучыбызга багышлап дога кылдык. Мәһдиевләр рухы белән яшәгән Сикертән, Гөберчәк авыллары җаннарыбызда тагын да якынрак, тагын да кадерлерәк булып калды.

Сикертән — мәшһүр драматургыбыз Галиәсгар Камалның әтисе Галиәкбәр абзый туган авыл да икән. Өй урыннарын хәзер дә беләләр. Монда, авыл янында, Галиәкбәр чишмәсе ага... Ул Кесмәс елгасына кушыла.

1917 елгы революция чорларында, Сикертәндә имам-хатыйп булып Фатыйх Әмирханның әнисенең энесе Габдулла Хәсәнов эшләгән. Бу якларда Шиһабетдин Мәрҗанинең авылдашы, мәшһүр Кышкар мәдрәсәсендә укып мулла булган Хәким хәзрәт тә яшәгән. Аның бай китапханәсе дә булган.

Гомумән, Сикертән китаплы авыл исәпләнгән. Киявебез — 2004 нче елга кадәр Сикертән урта мәктәбе директоры булган Фаяз Хәмидуллин, миңа үзләрендә сакланган бер букча иске китаплар бирде. Алар арасыннан 1840 елда Казан университеты нәшриятендә басылган «Кыйссаи Сәйфелмөлек» китабы да килеп чыкты. Ул Яңа Кишет авылы кешесе Рәхмәтулла Әмирхан улының хәражәте белән басылган. Бу бит шуннан бер ел алда гына «Йосыф-Зөләйха» китабын беренче тапкыр типографиядә бастырып тараткан кеше! Аны замандашлары «Рәхмәй тылмач» дип йөрткәннәр. Гарәп, фарсы, урыс телләрен әйбәт белгән бу зат профессор Готвальд көтепханәсендә тәрҗемәче вазыйфасын башкара, бер үк вакытта Казан губерна идарәсендә ниндидер чиновник та була.

Сикертәндә табылган иске китаплар



Сарманнан килгән зиярәт кылучылар Мөхәммәт Мәһдиев кабере янында. Чардуган эчендә язучының апасы Җәүһәр ханым белән Дамир Гарифуллин. 29 август 2000 ел.

арасында Әхмәтһади Максудиның «Әлифба» китабы, берничә кулъязма китап өлешләре, «Бакырган», «Кыйссаи Йосыф», «Тарих гомуми» китапларының битләре дә бар иде... Нишләмәк кирәк, халкыбыз кебек үк, китапларыбыз да утлар-сулар кичкән шул...

Мөхәммәт Мәһдиев төбәгендә өч көн, өч төн туй ясап, кайтыр юлга чыктык. Күңелдә бастырыклап өелгән хатирәләр. Кесмәс елгасы дулкыннары үзара сөйләшә-сөйләшә безнең белән саубуллашып йөгерәләр. Аларга яр буендагы таллар кушылып, чуклы яулыкларын болгый-болгый безне озата баралар... Әнә, Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләрендә мәңгеләштерелгән урманның Тупы почмагы да үрелеп-үрелеп безгә карап кала. «Чулпан» исемен йөртүче хуҗалык үзәге Сикертәнгә Чулпан исемле кызыбызны килен итеп калдырып, Сарманга юл тоттык без ул чакта...

2006 елның 8 июлендә янәдән Сикертән, Гөберчәк авылларында булырга туры килде. Гөберчәктә Мөхәммәт Мәһдиев музее белән янәшәдәге иске мәктәпнең алгы ягына яңа мәктәп нигезен сала башлаганнар иде. Яңа уку елына мәктәп төзелеп тә беткән. Шулай итеп, «Пәйгамбәр абыебыз» (язучы Әхәт Гаффар сүзе) Мөхәммәд Мәһдиев теләгәнчә, авылның мәгариф-мәдәният-тарихи үзәге барлыкка килгән. Быел асфальт юлны да Сикертәнгә, аннан Гөберчәккә сузганнар. Димәк, соңарып булса да, язучының тагын бер теләге тормышка ашкан.

Иллюстрацияләр авторның шәхси архивыннан.

Дамир Гарифуллин

РЕЗЮМЕ

Статья писателя-краеведа Д. Гарифуллина посвящена татарскому писателю и литературоведу Мухаммеду Магдееву, описанию прошлого и настоящего деревень Губурчак и Сикертань Арского района Республики Татарстан.